СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail:Kach.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Кәче авыл җирлеге**
**Советы карары**

**«26» февраль 2024 ел** **№ 99**

**«Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Кәче авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2019 елның 13 маендагы 81 номерлы Кәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (22.09.2020 №6, 29.12.2021 №41, 30.09.2022 №62, 19.12.2022 №70 үзгәрешләр белән)**

«Муниципаль хезмәт турында» 25.06.2013 № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 13 сентябрендәге 987 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затлары хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 № 182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 17.09.2022 №1015 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге уставы нигезендә, Кәче авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Кәче авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында»2019 елның 13 маендагы 81 номерлы Кәче авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) муниципаль вазыйфаларны даими нигездә башкаручы затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 3 абзацын (4 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең штат расписаниесенә бухгалтер вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңгә кадәр кеше тора».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында Җирлекләр бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гәрәев